РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ
ЧЕРЕМШАНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
ул. Советская, д.32, село Черемшан, 423100

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
СОВЕТЫ
Совет урамы, 32е йорт, Чирмешән авылы, 423100

тел./факс +7(84396) 2-59-00, email: cheremshan@tatar.ru, http://cheremshan.tatarstan.ru

28.12.2022 ел №157

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы Советы
**КАРАРЫ**

«Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Контроль-хисап палатасы аппараты штатын раслау турында» 2012 елның 23 гыйнварындагы 76 номерлы Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Бюджет өлкәсе хезмәткәрләренең Хезмәткә түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган бюджет өлкәсе аерым оешмалары хезмәткәрләренең вазыйфа окладлары күләмнәрен арттыру һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 30 мартындагы 195 номерлы «Бюджет өлкәсе хезмәткәрләренең Хезмәткә түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган бюджет өлкәсе аерым оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт шартлары турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2022 елның 17 сентябрендәге 1013 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Карары, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Советы **КАРАР КЫЛДЫ:**

1. «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Контроль - хисап палатасы аппараты штатын раслау турында» Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Советының 2012 елның 23 гыйнварындагы 76 номерлы карарының 2 пунктын бәян итәргә: «2. «Бюджет өлкәсе хезмәткәрләренең Хезмәткә түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган бюджет өлкәсе аерым оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт шартлары турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 30 мартындагы 195 номерлы карары нигезендә акчалата тәэмин итүне билгеләргә».

2. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2023 елның 01 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының рәсми сайтында Интернет телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны җирле үзидарә, Совет регламенты, хокук тәртибе, экология һәм халыкның куркынычсызлыгы буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы Башлыгы,
Чирмешән муниципаль районы Советы рәисе Р.Т. Айбатов